

2025 елнын 14-17 февралендә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында Казанда татар теле һәм әдәбияты буенча тобәкара олимпиада узды.
Чара РФ субъектларынын мәгариф идарәсе органнары белән тозелгән белем бирv олкәсендә хезмәттәшлек турында килешvләрне гамәлгә ашыру, туган (татар) телнен дәрәжәсен һәм укучыларнын белем дәрәжәсен кvтәрv, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына гамәли ярдәм кvрсәтv максатыннан уздырылган. Олимпиадада Россиянен 22 субъектыннан - Мәскәv шәһәреннән, Мордовия, Чуваш, Марий Эл, Башкорттостан Республикаларыннан, Пенза, Саратов, Самара, Тvбән Новгород, Ульян, Әстерхан, Удмурт, Киров, Перьм, Омск, Оренбург, Томән, Чиләбе, Красноярск, Новосибирск, Свердловск, Курган олкәләреннән бер йоз алтмыш биш VIII, IX, X, XI сыныф укучылары - татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларнын топ этаплары жинvчеләре һәм призерлары катнашкан. Шул исәптән татар теле һәм әдәбияты буенча Мордовия республикасы турында жингән укучылар да ана теле буенча белемнәрен сынадылар.
Мордовия мәгариф министрлыгы исеменнән Равза Мокатдәс кызы Юмаева житәкчелегендә Ләмберә районы Татар Тавла урта мәктәбе 8 сыйныф укучысы Абузярова Зарина белән 9 сыйныф укучысы Салькаева Сафина (укытучылары А.Ф.Муртазина); Абуткина Аэлина, Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе 10 сыйныф (укытучысы С.Р.Поташова ); Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе 11 сыйныф укучысы Сафарова Зухра (укытучысы С.С.Саляева); Кадошкино урта мәктәбе 10 сыйныф укучысы Кильдеева Дарина (укытучысы З.Х.Кильдеева); Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе 11 сыйныф укучысы Бикмурзина Зухра (укытучысы Р.М.Юмаева); Ләмберә районы Аксен урта мәктәбе 11 сыйныф укучысы Бадретдинова Хабиба (укытучысы А.Ф.Абдюшева); Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе 9 сыйныф укучысы Карабанов Салават (укытучысы Ф.Ф.Боярова) ярышта катнаштылар.
Регионара олимпиадасынын татар теле һәм татар әдәбияты, нәфис сvз турлары vткәч, Идел буе дәvләт физик культура, спорт һәм туризм университетынын концертлар залында чараны ябу тантанасы узган. Быел Мордовиядән регионара олимпиадасында катнашкан һәрбер укучы - ПРИЗЕР.
Мордовия укучылары командасын олимпиадада житәкләгән Равза Мокатдәс кызы Юмаева һәрбер укучы очен ихластан жан атып, алар очен шатланып торды. Әлеге ярыштан алган хис-кичерешләре белән бvлеште һәм:
- Укучыларнын Казанда да сынатмый, югары нәтижәләргә ирешvе остазларынын, укучыларынын һәм аларнын гаиләләренен кvпъеллык хезмәтен, тырышлыгын раслый. Мин алып барган укучыларыбыз туган телләре белән горурланып яшәрләр, бервакытта да онытмыячакларлар, балаларына да ойрәтәчәкләр дип уйлыйм. Олы рәхмәтемне ягымлы, итагатьле балалар тәрбияләгән әти-әниләренә, ныклы белем һәм телебезне яратырга ойрәткән укытучыларына, Тобәкара олимпиадасын оештыручыларга аерым рәхмәтымне белдерәсем килә.
Ә олимпиада Программасы белән каралган чаралардан тыш, укучыларыбыз Казаннын истәлекле урыннары белән танышуны vз эченә алган мәдәни экскурсиядә булдык,

Галиәскәр Камал һәм Кәрим Тинчурин театрларында спектакльләр тамаша кылдык. Галиәскәр Камал театрында эстрадабызнын легендар йолдыз жырчыбыз Альфия Авзаловага багышланган «Мәнгелек юл» дигән премьераны елый-елый, барлык хисләребез ургылып чыкканчы карадык.
Укучыларыбыз әлеге чарадан алган эмоцияләрен гомерләре буенча сагынып сойләрләр.

**Наилә НАСЫРОВА**